#  Мәктәп хәбәрчесе

**№4**
**(№7)**
**апрель**
**2019 ел**

*Түбән Майна урта мәктәбе гәзите*


**Тел. 8 (84344) 4-38-46** **sch1644maina@mail.ru**

**/Укытучы сүзе /**

### *Замана авыруына бирешмик*

Соңгы елларда **кесә телефоннары** тормышыбызга шулкадәр нык үтеп керде ки, ул хәзер әби кулында да, бәби кулында да. Нинди маркадагы һәм нинди бәядәгеләре генә сатылмый телефоннарның. Һәрбер техник җиһазның файдасы булган кебек, кесә телефонының да уңайлыклары бик күп. Бүгенге көндә ул сөйләшү чарасы гына түгел, ә үзең белән бергә йөрүче интернет, радио, телевизор, почта, фотоаппарат, видеокамера һәм башка бик күп функцияләргә ия искиткеч җайланма булып тора.

Сүз дә юк, әгәр кесә телефоны кирәкле эш өчен генә файдаланса, уңайлы әйбер. Ләкин тормыштагы һәрнәрсә **чамалы** булганда гына файдалы. Бүгенге яшүсмерләрне карасак, кирәксә дә, кирәкмәсә дә тәүлек буена телефоннарыннан аерыла алмыйлар. Өйдә, урамда, мәктәптә дә колагына кесә телефонын куеп сүз куерталар, үзара язышалар. Кечерәк балалар өчен телефон уенчык ролен уйный, аларны яңадан-яңа уеннар кызыксындыра. Бүген хәтта бакча яшендәге балалар да ата-аналарыннан кәрәзле телефон сорап аптырата.

Фәнни тикшеренүләр нәтиҗәсендә кесә телефонының сәламәтлек өчен куркыныч булуы ачыкланды. Белгечләр раславынча, алардан еш файдаланучылар **баш авыртудан, даими йокы килүдән, ярсучанлыктан** башкалар белән чагыштырганда күбрәк зарланалар икән. Кесә телефоны, бүтән җиһазлардан аермалы буларак, эшләгәндә ми һәм күзләргә бик якын тора. Аннан чыккан электромагнит нурланышы тукымаларга үтеп кереп аларны җылыта һәм әлеге тәэсир организмның функцияләре бозылуына китерә. Бигрәк тә моңа нерв, йөрәк-кан тамырлары эндокрин системасы сизгер. Галимнәр кесә телефоныннан даими файдаланучыларның **иммунитетына** куркыныч янавы турында да кисәтә.

**Күз күреме начарлану** – кесә телефоны китергән иң зур зыяннардан дисәк ялгышмабыз. Телефонның кечкенә экранына озак вакытлар текәлеп утыру күзләр өчен зур киеренкелек тудыра. Бу хәл аеруча балалар һәм яшүсмерләрнең ныгып җитмәгән күзләре өчен зыянлы. Безнең мәктәп укучылары арасында начар күрүчеләрнең арта баруы турыдан-туры кесә телефоны белән мавыгуга бәйле.

Укучыларда **фикерләү сәләтенең түбәнәюе** дә теләсә инди кирәкле мәгълүматны әзер килеш интернеттан алу мөмкинлеге белән бәйле. Белгәнебезчә, моның өчен яшүсмерләр арасында компьютердан бигрәк кесә телефоннары еш файдаланыла.

Кесә телефонының тагын бер зыяны – **кешенең психикасына тискәре тәэсир** итүдә. Психиатрлар телефонга бәйлелекне психик авыруның яңа формасы дип ышандыралар. Телефоннан күп сөйләшүчеләр, наркоманнар кебек үк, үзләренең телефонга бәйле булуларын, моның авыру икәнен танырга да, аңларга да теләми. Әлеге **бәйлелек чиренең** беренче билгеләре көненә телефоннан 30 минуттан да артыграк сөйләшү яки аны башка максатларда куллану. Кесә телефонының функцияләре күбрәк булган саен, телефон хуҗасының психик планда "наркоман" булу куркынычы да арта.

Югарыда китерелгән зарарлы факторларны күздә тотып быелгы уку елында безнең **укучыларга мәктәпкә телефон белән керү тыелды**. Ләкин укучыларның күп вакыты мәктәптән тыш узганлыктан, балаларының кесә телефоны белән эш итүен ата-аналар да игътибар үзәгендә тотсыннар иде.

***Алсу Сафиуллина. Тәрбия эше буенча директор урынбасары***




**/Рәсми хәбәрләр/**

Апрель аенда мәктәптә 4-7 һәм 11 сыйныфларда Бөтенроссия тикшерү эшләре үткәрелде. Эшләрнең графигы һәм нәтиҗәләре түбәндәге таблицада китерелә.

| Дата | Сыйныф | Предмет | Уртача билге |
|---|---|---|---|
| 02.04. | VII | Инглиз теле | 3,6 |
| 04.04. | VII | Җәмгыять белеме | 3,4 |
| 09.04. | VII | Рус теле | 3 |
| | VI | География | 3,1 |
| 11.04. | VI | Тарих | 3,8 |
| | XI | География | 4,4 |
| 16.04. | V | Тарих | 3,1 |
| | VI | Биология | 3 |
| | IV | Рус теле (1) | 3 |
| 18.04. | V | Биология | 4 |
| | VI | Җәмгыять белеме | 3,3 |
| | VII | Математика | 4 |
| | IV | Рус теле (2) | 3 |
| 23.04. | V | Математика | 4 |
| | VI | Рус теле | 3,3 |
| 24.04. | IV | Математика | 4 |
| 25.04. | VI | Математика | 3,3 |
| | V | Рус теле | 3,2 |
| 26.04. | IV | Әйләнә-тирә дөнья | 4 |

Узган айда мәктәптә Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм тикшерү департаменты комиссиясе тикшерүләре булып үтте. Тикшерү белем бирү сыйфаты, дәүләт һәм лицензия күзәтчелеге юнәлешләре буенча үткәрелде. Нәтиҗәләре 08.05. билгеле булачак.

## *Онытылмас сәяхәт*





Без 26 апрель көнен түземсезлек белән көттек. Чөнки бу көнне әле узган елда ук планлаштырылган Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләренә сәяхәтебез башланды. Менә ниһаять, 15 кешелек укучылар төркеме, укытучылар җитәкчелегендә мәктәп автобусы белән Казан шәһәренә юнәлдек. Бу көн Бөек **Тукайның туган көне** булганлыктан, сәяхәтебезне аның музеена керүдән башладык. Ремонттан соң әле яңа гына ачылган музей безне үзенең экспонатлары белән гаҗәпләндерде. Музей белгече Тукайның тормышы, иҗат дәвере турында тәфсилләп сөйләде. Казанда без озак булмадык. Шул көнне кич Казан-Мәскәү поездына утырып башкалага юл тоттык. Күпләребез өчен поезд белән тәүге тапкыр танышу үзе бер вакыйга булды.

Менә иртән үк поезд безне Мәскәүнең Казан вокзалына китереп җиткерде. Вокзалда сәяхәтебезне файдалы һәм кызыклы итеп оештыручы Лилия апа белән гид Татьяна апа каршы алдылар. Автобуста Мәскәүнең тарихи урыннары турында Татьяна апа мавыктыргыч итеп сөйләп барды. Беренче тукталышыбыз **ВДНХ** янындагы **Космонавтлар аллеясында** булды. Шуннан **Останкинога** барып андагы данлыклы телеманара һәм телестудия биналарын күрдек. Аннан автобус безне башкаланы күзәтү урыны булган **“Воробьевы горы”** дигән җиргә алып килде. Биредә без илнең иң зур уку йорты булган **МГУ**ның төп бинасы белән таныштык.



Мәскәү сәяхәтенең төп вакыйгалары Кремль тирәсендә дәвам итте. Башкаланың үзәгендәге **Зур театр** каршындагы **Революция мәйданында** безне Мәскәүнең күренекле гиды, КВНчы Олег абый каршы алды. Ул безнең төркемне ике командага бүлеп, бик җанлы квест оештырды. Ярышның төп өлеше Кремль янындагы **Александр бакчасында** һәм **Кызыл мәйданда** барды. Олег абый биргән рольләрне башкарып, төрле уеннарда катнашып, үзебез өчен Мәскәү турында күп яңалыклар алдык. Барлык биремнәрне дә үтәгәннән соң безнең төркемгә Кызыл мәйданда **Мәскәү ачкычы** һәм истәлекле бүләкләр тапшырылды. Шуннан соң сәяхәтебез **Кремль** эчендә урнашкан **“Оружейная палата”** музеенда дәвам итте. Биредә без тарих дәресләреннән генә таныш патша хәзинәләрен күрү бәхетенә ирештек.

Төштән соң сәяхәтебез **“Поклонная гора”** дигән җирдә урнашкан Бөек Ватан сугышы мемориаль комплексында дәвам итте. Биредә без сугыш елларында кулланылган төрле танк, самолетлар һәм башка күп төрле кораллар белән таныштык. Шулай да күбебез өчен иң ошаганы – **Планетарий** булды. Монда безгә төрле приборлар ярдәмендә физика законнарны турында төрле тәҗрибәләр күрсәттеләр. Йолдызлы күктә без белмәгән әллә нинди могҗизалар барлыгын, табигатьнең серлелеген, өйрәнәсе мәгълүматның чиксез икәнлеген күрдек.

Чираттагы тукталышыбыз **Мәскәүнең Җәмигъ мәчетендә** булды. Биредә эшләүче гид Вера апа мәчеттәге музей белән таныштырып, дини белемнәребезны арттырды. Шуннан соң мәчет ашханәсендә кичке ашны ашадык. Мәскәү сәяхәтенең соңгы чарасы – **“Ривер Палас” теплоходында** Мәскәү елгасы буйлап, төнге башкаланы күзәтү булды. Өч сәгатьлек төнге манзарадан соң, Ленинград вокзалына килеп, төнге сәгать бердә Санкт-Петербургка кузгалдык.

28 апрель иртәнге якта без Санкт-Петербургка килеп җиттек. Безне вокзалда гид Ярослава апа каршы алды.



Автобус экскурсиясе барышында ул безгә шәһәрнең урамнары, биналары, һәйкәл һәм каналлары турында мавыктыргыч итеп сөйләп алып барды. Беренче тукталышыбыз данлыклы **“Бакыр җайдак”** һәйкәле, **Адмиралтейство** һәм **Исаакий соборы** урнашкан **Сенат мәйданында** булды. Биредә фотоларга төшеп, төрле сувенирлар алгач, сәяхәтебезне **Нева проспекты** буйлап дәвам иттек. Аннан соң тагын **Сәнгать академиясе** каршындагы ярга куелган легендар **Сфинкслар** янында һәм Октябрь революциясе символы – **“Аврора” крейсеры** янында тукталдык.

Мәскәүнең үзәге Кремль булган кебек, Петербургныкы – Петр I төзеткән **Петропавел крепосте**. Анда кергәнче шуннан ерак түгел урнашкан Санкт-**Петербург Җәмигъ мәчетен** карадык. (Дәвамы – 3 биттә)



## *Яу кырында калган мөгаллим* /Күренекле шәхесләр /

Җиңү бәйрәме якынлашып килгән көннәрдә Бөек Ватан сугышында һәлак булган якташларыбызны тагын бер кат искә алабыз. Яу кырында ятып калган 90 нан артык авылдашыбыз арасында сугышка кадәр безнең мәктәптә хезмәт куйган укытучы **Залиев Харис Шәрәфетдин улы** да бар.

Харис абый 1910 елда Олы Тигәнәле авылында туа. Педагогик курслар тәмамлап, укытучы белгечлеге алганнан соң, 1932 елда Түбән Майна беренче баскычлы мәктәбенә эшкә җибәрелә. Моңа кадәр килеп киткән укытучылардан аермалы буларак Харис абый Майнаның Шәфик бабай кызы Нәсимәгә өйләнеп, авылда төпләнеп кала. **1936-1940 елларда мәктәп мөдире** вазыйфасын башкара. 1939-1940 уку елы нәтиҗәләре буенча районның ударник укытучысы исеменә лаек була. 1940 елда Залиев Харисны Югары Кыдырата мәктәбенә җибәрәләр. Ул шунда сугышка алынганчыга кадәр эшли.

Залиев Харис абый 1941 елның декабрендә мобилизацияләнә. Сугышка алынуга ук лейтенант званиесы бирелеп, 225нче Новгород укчы дивизиясенең 1347нче укчы полкында 5нче укчы рота составындагы 3нче взвод командиры булып хезмәт итә. Волхов, Ленинград, 3нче Балтик буе фронтларындагы сугышларда катнаша. 1942 елның 7 маенда Волхов плацдармындагы сугышлар барышында яралана. 1944 елның 17 июле көнне Псков-Остров операциясе барышында Залиев Харис взводы Псков өлкәсендәге Красногородск районы Гришеново авылы янында дошманның 3 пулемет ноктасын юк итә. Шул ук көнне Харис абый солдатлары, беренчеләрдән булып, Красногородск шәһәре читенә килеп чыга. Шуннан соң алар, уңышлы әйләнеш ясап, бер солдатны да югалтмыйча, шәһәрнең үзәгенә үк үтеп керәләр. 19 июль көнне бер урман читендә лейтенант Залиев взводы тагын беренче булып дошман белән сугышка керә. Әлеге һөҗүм барышында Харис абый, үз солдатларына кыюлык үрнәкләре күрсәтеп, батырларча һәлак була. Сугышта күрсәткән батырлыклары һәм взвод белән оста командалык иткәне өчен, Залиев Харис абый, үлгәннән соң **1-нче дәрәҗә "Ватан сугышы" ордены** белән бүләкләнә. Кабере Псков өлкәсе, Красногородск районы Бодренки авылы янында.

Хәзерге вакытта безнең мәктәптә Харис абыйның оныгының балалары **Вәсилә, Илдияр һәм Салават Залиевлар** укый. Без аларга батыр бабаларына лаеклы булып үсүләрен калабыз.

---

Биредә Ярослава апа татар халкы вәкилләренең шәһәр тарихында тоткан урыны турында сөйләде. Шуннан соң крепость эченә кереп, андагы төрмәләрне һәм Рәсәй императорлары җирләнгән Петропавел соборын карап чыктык.

Төштән соң **"Meininger" отеленә** урнашып, кафеда төшке ашны ашадык. Шуннан соң Ярослава апа безне **Эрмитажга** алып барды. Бу зур мәйданлы, искиткеч матур, зәвык белән бизәлгән патша сараеның һәр бүлмәсе һәм андагы сәнгать әсәрләре барчабызны да таң калдырды. Кеше куллары тудырган бу матурлыкны беркайчан да онытып булмас. Эрмитаждан чыккач Санкт-Петербург мәйданнары һәм урамнары буйлап сәяхәтебезне җәяүләп дәвам иттек. **Александр баганасы**, Пушкин соңгы юлга озатылган һәм патша Александр IIгә һөҗүм булган урындагы чиркәүләр, данлыклы **Казан соборы** белән якыннан таныштык. Кунакханәгә кадәр бер тукталыш арасын метрода кайттык. 70 метрдан да тирәндә Нева елгасы астыннан сузылган бу юл – Петербургның тагын бер могҗизасы.



Кичен кунакханәгә кайтып ял иткәннән соң, төн уртасында тын калган шәһәр урамнары, санап бетергесез каналлар аша барып, **ачылмалы күперләрне** күзәттек. "Дворцовый" күперенең төрле утлар белән балкып ачылуы, барыбыз өчен дә онытылмаслык матур манзара булды.

Сәяхәтнең соңгы көнендә автобус безне атаклы Петергоф бистәсенә алып китте. Юл уңаенда Ярослава апа **Ленинград блокадасына** бәйле урыннарны күрсәтеп, шәһәрнең сугыш чоры фаҗигасы турында сөйләп барды.

**Петергоф музей-тыюлыгы** безне искитмәле фонтоннары, су юллары, хикмәтле төзелеше, исәпсез күп скульптуралары белән каршы алды. Император Петр Iнең яшелчә бакчасы, карт имәннәре, Фин култыгы ярындагы йорты – безнең өчен чын тарихи һәйкәлләр булып хәтердә калды. Шунысы да бик мөһим – Бөек Ватан сугышы вакытында Петергоф тыюлыгы тулысынча диярлек җимерелеп бетсә дә, сугыштан соң халык тырышлыгы белән яңадан торгызылган.

Петергоф могҗизалары белән тәэсирләнеп, кайтыр юлга кузгалдык. Автобус безне вокзалга нәкъ вакытында китереп җиткерде. Шулай итеп, сәяхәтебезнең бер минуты да бушка узмады. Арып-талып поездагы урыннарыбызга кереп урнаштык. Бу юлыбыз инде **Туган якка** таба. Сагынышып, үз илебезнең кадерен, матурлыгын, байлыгын белеп кайттык. Бу сәяхәт безнең күңелләрдә мәңгегә сакланып калыр. Безгә шундый матур, истәлекле бәйрәм оештырган өчен мәктәп директоры Насыйров Рафик абыйга зур рәхмәтебезне белдерәбез.

**Зөлфирә Сафиуллина һәм Виктория Нукина, VII сыйныф укучылары**

## / Безнең уңышлар /



### Дәрестән тыш эшчәнлек

29 апрель көнне Аксубай спорт комплексында **“Куркынычсыз тәгәрмәч”** республика конкурсының район туры булып үтте. Конкурс 3 этапта узды, барлыгы 14 команда көч сынашты. Безнең мәктәп данын яклап, V сыйныф укучылары **Галимов Рияз, Гафиятуллин Самат, Минакова Әдилә** һәм **Нурматова Зәйнәп** катнаштылар. Укучылар I этапта велосипедларда фигуралы йөрүдә көч сынашты. II этап – теоретик тур – беренче медицина ярдәме күрсәтү, юл йөрү кагыйдәләрен, велосипед төзелешен белүгә багышланды. III этапта юл йөрү кагыйдәләрен белү буенча агитбригадалар конкурсы уздырылды. Безнең укучылары конкурс нәтиҗәләре буенча “Иң яхшы агитбригада ” номинациясендә 3 урын, гомуми команда нәтиҗәләре буенча 6 урын яулады. Юл хәрәкәте яшь инспекторларын әзерләүче җитәкчеләре – **Гафиятуллина Руфия Әмир кызы**.



Апрель аенда уздырылган **“Профессия”** дип исемләнгән фото һәм рәсем буенча район конкурсында катнашып, рәсем номинациясендә XI сыйныф укучысы **Галимова Нәзилә – призер**, фото номинациясендә IX сыйныф укучысы **Сәгъдиева Таңсылу – лауреат** исемнәренә лаек булдылар. (Остазлары – **Зарипова Зөлфия Дамир кызы**)

### Фәнни конференция



20 апрель көнне Казан шәһәрендә уздырылган **“Минем гаиләм тарихы”** Төбәкара гуманитар-мәгърифәти конференциясендә катнашып, VIII сыйныф укучысы **Насыйрова Сара** татар телендә башкарылган конкурс эшләре һәм чыгышлар буенча **җиңүче** исемен алып, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы дипломы белән бүләкләнде. (Остазы – **Насыйров Рафик Гомәр улы**).

### Спорт ярышы

14 апрель көнне көрәшче егетләребез Чистай шәһәрендә “Чистай электр челтәре” ААҖ призына **самбо көрәше** буенча уздырылган Республика беренчелегендә көч сынаштылар. Ярыш нәтиҗәләре буенча **Камалов Илдус** – I, **Нурматов Халид** – II урыннарны яуладылар. (Остазлары –**Камалов Илһам Илгизәр улы**)

## / Укучылар иҗаты /

### Күңелле мәктәп

Әй күңелле мәктәптә
Безнекендә бигрәк тә.
Ышанмасагыз – килегез
Үзегез дә күрерсез.

Укытучылар дәрестә
Юллый әллә кайларга
Тирән океаннар гизәбез
Бик кыска араларда.

Математик биремнәрне
Бик тиз исбат итәбез
Югалып беткән иксларны
Бик тиз табып бирәбез.

Лермонтов, Пушкиннар инде
Күптәнге дусларыбыз,
Тукай белән Җәлилнең дә
Дәвамчыларыдыр без.

Тарих бездә иң кызыгы,
Кандидат укытканга.
Ул музейда ни генә юк,
Авыл борынгы булганга.


Көрәштә билне бирмиләр
Бездәге нык малайлар.
Түгәрәккә йөргән кызлар
Бигрәкләр дә уңганнар.

Бик күңелле мәктәптә
Безнекендә бигрәк тә.

**Нәзирә Әхмәтова**
**VIII сыйныф укучысы**



## / Котлыйбыз! /




Апрель аенда дөньяга килгән балалардан: бакча төркеменнән Хафизов Ирекне, укучылардан Залиева Вәсиләне, Морадимов Илназны, Шәрифуллин Илсафны, Сафиуллин Илсурны туган көннәре белән котлыйбыз. Барыгызга да ныклы сәламәтлек, мәктәптә иң алдынгылардан булуыгызны телибез.

Хөрмәтле укытучыларыбыз Туктамышев Рифкать абый, Сафиуллин Илдар абый, Иванова Олеся апаларны гомер бәйрәмнәре белән тәбрик итәбез. Сезгә сәламәтлек, гаилә бәхете, эшегездә уңышлар теләп калабыз.

**Газетаны гамәлгә куючы** – Түбән Майна урта мәктәбе
**Мөхәррир** – Фәнүзә Гафиятуллина
**Редколлегия әгъзалары:**
Әминә Туктамышева
Виктория Нукина
Зөлфирә Сафиуллина
Алия Гыйззәтуллина
Нәзирә Әхмәтова
Рузилә Мөхәммәтова
Сара Насыйрова